МИНИСТЕРСТВО
ИНФОРМАТИЗАЦИИ И СВЯЗИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘГЪЛҮМАТЛАШТЫРУ ҺӘМ
ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ **БОЕРЫК**

07.12.2017 г.Казань № 9-07-МКНС

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә бәйгеләр уздыру турында» 2014 елның 05 сентябрендәге ПК-19 номерлы боерыгына үзгәрешләр керту турында

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә бәйгеләр уздыру турында» 2014 елның 05 сентябрендәге ПК-19 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге уздыру турында нигезләмәне кушымтада бирелә торган яңа редакциядә бәян итәргә;

Әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган рәвештәге, тутырылган һәм имзаланган анкета, фото белән;»;

унынчы абзацта «шәхси» сүзен төшереп калдырырга;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башка дәүләт органында вазыйфа биләүче, бәйгедә катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында министр исеменә шәхси гариза һәм үзе тутырган, имзалаган һәм үзе граждан хезмәтен били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формадагы анкетаны фотосын теркәп тапшыра.».

Министр вазыйфаларын башкаручы Д.В.Вандюков

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 2014 елның 5 сентябрендәге ПК-19 номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының 07.12.2017 № 3-07-ПК/15 боерыгы ред.)

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге уздыру турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге уздыру буенча бәйге комиссиясенең (алга таба – бәйге комиссиясе) эшләү вакытлары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы (алга таба – Министрлык) аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) бәйге уздыру методикасы билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге (алга таба – бәйге) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә карата тигез дәрәҗәдә үтеп керә алуы буенча конституциячел хокукларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) бәйге нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында бәйге «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законның 22 статьясы (алга таба – 79-ФЗ номерлы федераль закон), Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнарга тест уздыруны оештыру

мәсьәләләре» 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы указы нигезендә үткәрелә.

Бәйге дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүчеләрнең профессиональ дәрәҗәсен, аларның граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге Федераль закон нигезендә бәйге нигезендә биләнергә мөмкин булган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булганда мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрының (аның вазыйфаларын башкаручы затның) (алга таба – министр) карары белән игълан ителә.

1.4. Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә бәйге кадрлар бүлеге тарафыннан, Министрлыкның вакантлы граждан хезмәте вазыйфаларын биләү буенча белгечләргә мөмкин булган ихтыяҗын һәм Министрлыктагы кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Федераль законның 57 статьясының 1 өлешендәге 2 яисә 3 пунктында яки 59.1 статьясының 2 яисә 3 пунктында каралган дисциплинар йөкләмәсе булган дәүләт хезмәткәре Министрлыкның кадрлар резервына кертелә алмый.

Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә бәйге Министрлыкның бәйге комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.5. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге түбәндәге очракларда үткәрелми:

билгеле бер чорга биләнә торган «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен биләү өчен билгеләнгәндә;

вакытлы хезмәт контрактын төзегәндә;

Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен дәүләт граждан хезмәтенең бүтән вазыйфасына билгеләгәндә;

граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.6. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә бәйге түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Министрлык боерыгы нигезендә расланучы вазыйфалар исемлегендә аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

министр карары нигезендә, граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.7. Бәйге түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керүдә Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең бәйге нигезендә вазыйфада үсү хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны федераль законнарда, Татарстан Республикасы

законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм бәйгедә катнашуга кертелгән кандидатларның гомуми саны арасыннан сайлап алу;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.8. Бәйгеләрне үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатлар өчен дә алар тарафыннан бәйге биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

объектив һөнәри әһәмиятле критерияләр нигезендә кандидатларны бәяләү;

бәйгедә катнашучылар арасыннан, бәйге процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфалары (кадрлар резервына кертү) таләпләренә җавап бирә торган затларны ачыклау.

2. БӘЙГЕ КОМИССИЯСЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ҺӘМ АНЫҢ ЭШ ТӘРТИБЕ

2.1. Министрлыкта бәйге уздыру өчен министр боерыгы нигезендә даими нигездә эшләүче бәйге комиссиясе төзелә.

2.2. Бәйге комиссиясе Рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе бәйге комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда аның хокукларын һәм бурычларын бәйге комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Бәйге комиссиясенең сәркатибе бәйге комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризаларны кабул итү, эшләрне формалаштыру, бәйге комиссиясе утырышлары карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.4. Комиссия составына министр урынбасарлары, Министрлык бүлекчәләренең җитәкчеләре: Министрлыкның кадрлар, хокукый тәэмин итү бүлекчәләре җитәкчеләре, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге үткәрелә торган структур бүлекчәсе җитәчесе, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Министрлык каршындагы иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан Министр гаризасы буенча бәйсез экспертлар – граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр рәвешендә экспертларның персональ белешмәләрен күрсәтмичә чакыртыла торган фәнни, мәгариф һәм бүтән оешмаларның вәкилләре кертелә. Әлеге вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны бәйге комиссиясендәге әгъзаларның гомуми санынан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) бәйге уздырылганда бәйге комиссиясе составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турында законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Бәйге комиссиясе составы бәйге комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.7. Бәйге комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми исәбендәге кимендә өчтән ике өлеше катнашса, ул тулы хокуклы булып санала. Бәйге комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Бәйге комиссиясенең карары кандидат юклыгында кабул ителә.

2.9. Бәйге уздыру нәтиҗәләре буенча бәйге комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә аның утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, бәйге комиссиясе рәисе тавышы хәл иткеч була.

2.10. Бәйге комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиядә тавыш бирү нәтиҗәләре) бәйге комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, анда рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм бәйге комиссиясе утырышында катнашкан бәйге комиссиясе әгъзалары кул куя.

2.11. Бәйге үткәрүне һәм бәйге үткәрүне, бәйге комиссиясе эшен тәэмин итүне турыдан-туры оештыруны Министрлыкның кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

3. БӘЙГЕЛӘРДӘ КАТНАШУЧЫЛАР

3.1. Бәйгедә катнашуга Министрлыкның вакантлы граждан хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатларга карата тиешле таләпләргә туры килә торган һәм билгеләнгән чорда кирәкле барлык документларны тапшырган гражданнар кертелә.

3.2. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә җавап бирмәве, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләренә бәйле рәвештә гражданин (граждан хезмәткәре) бәйгедә катнашуга кертелми.

3.3. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен кандидатларга карата таләпләр дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнде.

3.4. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки закон белән саклана торган бүтән серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан биләү өчен дәгъва белдерелгән граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Гражданинның министр исеменә тапшырылган белешмәләренең дөрес булу-булмавы тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматлаштырылган рәвештә тикшерелә.

3.5. Бәйгедә катнашу теләген белдергән, Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре гаризаны министр исеменә тапшыра.

Бүтән дәүләт органында вазыйфа биләүче, бәйгедә катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә шәхси гариза һәм үзе тутырган, имзалаган һәм үзе граждан хезмәтен били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган формадагы анкетаны фотосын теркәп тапшыра.

3.6. Бәйгедә катнашу өчен документлар аларны кабул итү турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында игълан урнаштырылган көннән башлап 21 календарь көне эчендә дәүләт органына гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша җибәреп яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә күрсәтелгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, электрон рәвештә җибәрелә.

Хөрмәткә лаек сәбәпсез документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан (граждан хезмәткәреннән) аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Хөрмәткә лаек сәбәп аркасында документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда министр аларны кабул итү вакытын күчерергә хокуклы.

4. БӘЙГЕЛӘРНЕ УЗДЫРУ МЕТОДИКАСЫ

4.1. Бәйгене үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына таянган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган бәйге биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфаларына белдерелә торган квалификация таләпләренә туры китереп эшләнде.

Бәйге үткәрелә торган вазыйфаларның төркеменә һәм категориясенә карап, бәйгедә катнашучыларны бәяләү критерийлары һәм сайланган бәяләү методлары үзгәртелергә мөмкин.

Бәйгедә катнашучыларны бәяләү критерияләрнең үрнәк исемлеге һәм кыскача эчтәлеге шушы Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында китерелде.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу аларның бәйге биремнәрен үтәү һәм бәйге процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4. Бәйге ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта Министрлыкның кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

бәйге уздыру турындагы мәгълүматны әзерли һәм Министрлыкның рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыра, аңа түбәндәгеләр керә: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасының) исеме, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга куела торган таләпләр, граждан хезмәтен узу шартлары, кандидатлар тарафыннан

Министрлыкка дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итү тәмамланырга тиешле чор, бәйгене уздыру датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, башка материаллар;

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерүне:

гражданның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен тикшерә (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (бүтән төрле граждан хезмәтенең) стажы яки белгечлеге буенча эшләү стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәре һәм күнекмәләре).

4.4.2. Тикшерү барышында гражданинның Федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар ачыкланган очракта, аңа бәйгедә катнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында министр тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә. Әгәр гражданин бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган булса, бәйгедә катнаштырудан кире кагу сәбәпләре хакында белдерү аңа дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.4.3. Бәйгедә катнашуга кертелмәгән, вакант вазыйфаны биләү өчен дәгъва кылучы бу карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.4.4. Министрлыкта граждан хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата куелган квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидатның булуы бәйгенең беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаганда яисә вазыйфага карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган бары тик бер генә кандидат булган очракта, бәйге узмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка таләп ителүче кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә бәйгенең узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.4.5. Бәйгенең беренче этабы тәмамлангач министр бәйгенең икенче этабын уздыру датасы (катнашу өчен документлар кабул итү тәмамланганнан соң 30 календарь көне узганчы), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга рөхсәт рәсмиләштерелгән очракта, бәйгенең икенче этабын уздыру чорын министр билгели.

Кадрлар бүлеге, бәйгенең икенче этабы башланырга кимендә 15 календарь көн кала, Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында аның уздырылу датасы, урыны һәм вакыты хакында мәгълүмат урнаштыра һәм кандидатларга тиешле хәбәрләрне язмача рәвештә юллый, бу вакытта бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат

системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә.

4.4.6. Бәйгенең икенче этабында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

бәйге комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары бәяләнә;

Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертегә) бәйгедә җиңүчене билгеләү турында бәйге комиссиясе карары кабул ителә.

4.4.7. Бәйге уздырганда бәйге комиссиясе кандидатларны белеме, граждан хезмәтен яки бүтән дәүләт граждан хезмәтен үтәү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында алар тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү буенча Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган методлардан файдаланып, шул исәптән Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле мәсьәләләрдә тест һәм шәхси әңгәмә уздыру юлы белән, тест уздыру һәм бүтән төрле бәйге процедуралары нигезендә бәяли.

4.4.8. Министрлыкта дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына керүгә) дәгъва белдергән кандидатларга тест уздыру Татарстан Республикасы Президенты каршында Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты раслый торган Тест уздыру методикасына туры китереп гамәлгә ашырыла.

4.4.9. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатлары бәйге комиссиясе әгъзалары тарафыннан шулай ук аерым әңгәмә барышында бәяләнә.

4.5. Бәйге комиссиясенең бәйге комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән карары (әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта) бәйгенең икенче этап нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта бәйгенең йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.6. Кандидатлар тарафыннан алынган тавышларның саны, кандидатлар шундагы вазыйфага дәгъва белдерә торган структур бүлекчә җитәкчесенең фикере Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) кандидат турында карар кабул итү һәм бәйгегә йомгак ясау өчен нигез булып тора.

Бәйге комиссиясе бәйгедә җиңүче турында карарлар, шулай ук Министрлыкның кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатлар исемлекләрен раслый.

4.7. Бәйге уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланган очракта, бәйге комиссиясе өстәмә бәйге сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа бәйге уздыру турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.8. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен бәйге нәтиҗәләре нигезендә бәйгедә җиңүчене граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында министр боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Бәйге комиссиясе шулай ук тәкъдим рәвешендәге, граждан хезмәтенең биләнми торган вазыйфасын биләү өчен бәйгедә җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган катнашучыны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Күрсәтелгән карар Министрлыкның

кадрлар резервына кертү турында кабул ителгән очракта, әгәр кадрлар резервына кертүгә кандидат башка дәүләт органында вазыйфа биләп торса, Министрлыкның тиешле дәүләт хакимияте органының кадрлар хезмәтенә кандидаттан әлеге Нигезләмәнең 1.4 пунктының икенче абзацы нигезендә дисциплинар йөкләмәсе булу-булмавы турында сорап, гариза ясый.

Кандидатның ризалыгы белән, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы караган шул ук төркем граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен, аны кадрлар резервына кертү турында министр боерыгы чыгарыла.

Граждан хезмәткәрен (гражданинны) – бәйгедә җиңүчене кадрлар резервына кертү министр боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.9. Бәйге нәтиҗәләре хакында хәбәрләр ул тәмамланганнан соң 7 көнлек чорда кандидатларга язмача рәвештә, бу вакытта бәйгедә катнашу өчен документларны электрон рәвештә тапшырган кандидатларга дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Шушы ук чорда бәйге нәтиҗәләре турында мәгълүмат Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең күрсәтелгән мәгълүмат системасында да урнаштырыла.

4.10. Кандидат бәйге комиссиясе карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.11. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) дәгъва белдергән, ләкин бәйгедә катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм бәйгедә катнашкан кандидатларның документлары язма гаризалары буенча бәйге тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Бәйгедә катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

4.12. Бәйгедә катнашуга бәйле чыгымнар (бәйге үткәрелгән урынга бару һәм кайту, торак бинага түләү, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкасы) кандидатлар тарафыннан үз акчалары хисабыннан түләнә.

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм
элемтә министрлыгының 2014
елның 5 сентябрендәге № ПК-
19 боерыгына 1 нче кушымта

БӘЙГЕ КОМИССИЯСЕ КАРАРЫ № ____

Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының бәйге комиссиясе утырышында биләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфага (кадрлар резервына кертүгә) бәйге аша сайлап алу буенча тавыш бирелде

_____.
(биләнә торган вакантлы вазыйфа аталышы)

Утырышта _____ бәйге комиссиясе әгъзасының ____ катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
1. _____ «хуплый» _____ «каршы» _____.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
2. _____ «хуплый» _____ «каршы» _____.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
3. _____ «хуплый» _____ «каршы» _____.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тавыш бирү нәтиҗәсендә:
_____
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
бәйге комиссиясе әгъзаларыннан иң зур санда баллар алды һәм Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына бәйгедә җиңүче булып тора.

Тавыш бирү нәтиҗәсендә:
_____.
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгының кадрлар резервына кертелде.

Бәйге комиссиясе рәисе _____ _____
(имза) (тулы имза)
Бәйге комиссиясе рәисе урынбасары
_____
(имза) (тулы имза)
Бәйге комиссиясе сәркатибе _____ _____
(имза) (тулы имза)
Бәйге комиссиясе әгъзалары _____ _____
(имза) (тулы имза)
_____
(имза) (тулы имза)

Бәйгене үткәрү датасы «__» _____ 20__ ел.

Татарстан Республикасы
Мәгълүматлаштыру һәм элемтә
министрлыгының 2014 елның 5
сентябрендәге №ПК-19
боерыгына 2 нче кушымта

БӘЙГЕЛӘРДӘ КАТНАШУЧЫЛАРНЫ БӘЯЛӘҮ БИЛГЕЛӘРЕ

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте мәдәниятенә туры килүе

1.1. Һөнәри максатчанлыгы

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә һөнәрдә шәхси потенциал үстерүгә омтылуы, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәттә үсүне күздә тотуы.

1.2. Гражданлык позициясе

Эшчәнлектә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итү, законнарны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен саклау принципларын үтәү.

1.3. Һөнәри позициядәге активлыгы

Куелган мәсьәләләрне хәл иткәндә инициатива күрсәтергә омтылуы; мөмкин булган иң яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен хәлдән килгәнчә тырышлык күрсәтергә әзер булуы, физик һәм эмоциональ басым шартларында нәтиҗәле эш-гамәл кылуга (стрессларга каршы торуга) сәләтле булуы.

1.4. Үз-үзен үстерүгә әзер булуы

Үз белемнәреңне, осталыкларыңны һәм күнекмәләреңне даими камилләштерергә, карашларыңны киңәйтергә, катнаш һөнәр өлкәләрендә белемнәр һәм тәҗрибә алырга омтылу.

2. Кандидатның һөнәри вәкаләтлелеге

2.1. Белем дәрәҗәсе

Төп һәм өстәмә һөнәри белем дәрәҗәсе, юнәлеше һәм сыйфаты.

2.2. Һөнәри тәҗрибәсе

Тиешле һөнәр өлкәсендәге эшчәнлек итү озынлыгы һәм үзенчәлекләре; һөнәри

эшчәнлегендә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешүе; карьерасының үзенчәлекләре.

2.3. Махсус һөнәри белемнәре, осталыклары һәм күнекмәләре

Тиешле өлкәдә, вазыйфаи бурычларны нәтиҗәле хәл итү мөмкинлеген бирә торган һөнәри белемнәренең дәрәҗәсе; эшчәнлек юнәлеше буенча, һөнәри эшчәнлекне регламентлый торган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын белүе; заманча һөнәри технологияләр белән эш итә белүе.

2.4. Гомуми инструменталь күнекмәләре

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелеген арттыра торган күнекмәләргә ия булу дәрәҗәсе (компьютер белүе, гомуми грамоталылыгы, чит телләр белү).

3. Кандидатның шәхси-эшлекле сыйфатлары

3.1. Аналитикага бәйле сәләтләре

Катлаулы мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеген бирә торган, мәгълүматны анализлауны һәм структуралаштыруны таләп итүче системалы һәм сыгылмалы фикерләү дәрәҗәсе; яңа, гадәти булмаган чишелешләрне табуга сәләтле булуы.

3.2. Нәтиҗәле коммуникацияләү күнекмәләре

Эшлекле сөйләм этикасын саклавы; үз фикерен дәлилләп яклау һәм оппонентларны ышандыру сәләте; эшлекле сөйләшүләр алып бару күнекмәләренә ия булуы.

3.3. Җаваплылыгы

Карарларны кабул итүдә нигезле һәм мөстәкыйль эш итүе; нәтиҗәгә ирешүдә үз өстенә алган йөкләмәләрне үтәргә әзер булуы.

3.4. Оештыруга бәйле сәләтләре

Үз эшчәнлегеңне һәм сиңа буйсынып эшләүчеләр эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, вазыйфаларны, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлеп бирү хисабына нәтиҗәләргә ирешә белү.